Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XIII-10**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 30 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге XXVIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Котлы Бөкәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, 2021 елның 3 сентябрендә уздырылган ачык (гавами) тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге XXVIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Котлы Бөкәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Котлы Бөкәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең “Ж-1 - индивидуаль торак йортлар төзү зонасы” бүлеге таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез мөлкәтне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның кыйммәтләре | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы бер гаиләлек йорт | Блокланган йортта бер гаиләгә торак берәмлеге |
| **Җир кишәрлекләренең иң чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 1000 | 1000 |
| Максималь мәйдан | кв.м | 2500 | - |
| Урам (юл йөрү) фронты буйлап минималь киңлек | м | 12 | 6 |
| **Кишәрлекләр чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары** | | | |
| Кишәрлек төзелешенең максималь проценты | % | 40,5 | 55 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән төзелмәләрнең минималь чигенеше (калган аралыгы) (төзелешне җайга салу линиясе белән башка күрсәткеч билгеләнмәгән очракларда) | м | 3 | 3 |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән төзелмәләрнең минималь чигенеше (калган аралыгы) | м | а) 1- брандмауэр (янгынга чыдам) дивар мәҗбүри булганда;<br>б) 3 – башка очракларда | а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда;<br>б) 3 - башка очракларда |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кишәрлекнең арткы чигеннән төзелмәләрнең минималь чигенеше<br><br>(калган аралыгы) (төзелеш эшләрен җайга салу линиясе белән башкасы билгеләнмәгән булса | м | 3 | 3 |
| Төп төзелмә катларының иң чик саны (мансард катын да кертеп) | кат | 3 | 3 |
| Төзелмәләрнең максималь биеклеге | м | 10 | 10 |
| Ярдәмче төзелмәләр катларының иң чик саны | кат | 1 | 1 |
| Ярдәмче төзелмәләрнең иң чик биеклеге (яссы түбә/скат түбә) | м | 3,5/4,5 | 3,5/4,5 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2* | 2* |

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 июнендәге XXVIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең кушымтадагы редакциядә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясеннән файдалануның шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына һәм махсус шартлары булган картасына үзгәрешләр кертергә һәм расларга:

кадастр номеры 16:34:130103:149, мәйданы 911 кв.м булган, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Котлы Бөкәш авыл җирлеге, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 48А йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген үз эченә алган территориягә карата индивидуаль торак йортлар өчен (Ж1) төзелеш зонасын билгеләү өлешендә.

3. Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов